СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

*1 октябрь, 1997ел.*
**ЧӘРШӘМБЕ**

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 110 (8122)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

## 1 октябрь - Өлкәннәр көне

# ӨЛКӘННӘРНЕ ХӨРМӘТ ИТМӘГӘННӘР ҮЗЛӘРЕ ДӘ БУЛМАС ХӨРМӘТЛЕ...

## КОТЛАУ

**Календарьда менә тагын көз уртасындагы айның беренче көне. Традиция буенча без ул көнне бәйрәм вакыйгаларының башка берсенә дә охшамаган көнне - өлкәннәр көнен рәсми төстә билгеләп үтәбез. Безнең пенсионерларыбыз, кадерле бабаларыбыз һәм әбиләребез, әтиләребез һәм әниләребез өчен 1 октябрь - ул узган гомер һәм кичерелгән язмышлар турында якты хатирәләр, дуслар һәм иптәшләр белән, элеккеге хезмәттәшләр белән шатлыклы очрашулар, шул ук вакытта үтеп баручы вакыт турында моңсу уйларга бирелү көне дә. 1 октябрь - буыннар очрашуы бәйрәме. Гомумән алганда ул барыбер оптимистлык һәм ышану тантанасы. Чөнки бүгенге нинди генә таркаулыклар да сугыш утын кичкән, җимереклекләр, ачлык - ялангачлык ачысын татыган һәм шуларга да карамастан йөрәкләрендә ватанпәрвәрлек һәм интернациональлекнең тирән хисен, изгелек һәм кешелеклелек, хаклык һәм гаделлеккә ышаныч хисен дистә еллар буена саклап кала алган өлкән буын кешеләренең героик рухын сындыра алмыйлар.**

**Сез, кадерле ветераннар, бүген Ватаныбызның тарихын гәүдәләндереп кенә калмыйча, безнең өчен түземлелек һәм ныклык үрнәге дә булып торасыз, үзегезнең бәяләп бетергесез тормыш һәм әхлакый тәҗрибәгезне, яшәү зирәклеген, кыенлыкларны җиңә алу сәләтегезне армый - талмый бүгенге буыннарга тапшырасыз. Сезгә, безнең кадерлеләребез, тормыш бөтенлеге, тазалык - саулык, озын гомер һәм сезне яратучы балаларыгыз һәм оныкларыгының мәхәббәтен тоеп тыныч картлык кичерүегезне теләп калабыз.**

***Сезгә иң изге теләкләр белән:***
***Ф.СИБАГАТУЛЛИН, халык депутатларының район Советы рәисе, район хакимияте башлыгы.***



***Гомернең кояш баешы.Күзләрнең җетелеге,битләрнең алсулыгы уңган.Чәчләр агарган,йөздә тирән буразналар.Аларның һәрберсендә-аерым тарих,аерым хатирә, аерым гамь.Кеше язмышы гомер азагында шулай сырлар булып биткә ята икән.Бары елмайганда гына алар бераз язылып, яктырып китәләр.***

***Ә еш елмаямы соң безнең өлкәннәребез? Без бу хакта уйланганыбыз бармы? Бу җыерчыкларда безнең дә битарафлыгыбыз, каты күңеллелегебез ятмыймы?***

***Ә безне нинди картлык көтә? Уйлан, кеше.Уйлан, кешелек.***

## Рәсми хәбәрләр

# Рәис алышынды

24 сентябрь көнне Синдряков исемендәге крестьян һәм фермер хуҗалыклары ассоциациясе членнарының гомуми җыелышы булды.Җыелышта башка эшкә күчерелү сәбәпле,хуҗалык рәисе С.И.Белогубов вазифаларыннан азат ителде.Рәис итеп шул ук хуҗалыкта бүлекчә управляющие булып эшләгән Вәгыйзь Минзарип улы Әбдрәхимов сайланды.

***

Шул ук көнне «Норлат шикәр заводы» АҖ ярдәмче хуҗалыгында да гомуми җыелыш узды.Анда ярдәмче хуҗалык рәисе Егоров Виталий Петрович шәхси гаризасы нигезендә вазифаларыннан азат ителде.Ярдәмче хуҗалык рәисе итеп моңарчы Синдряков исемендәге КФХАны җитәкләгән Сергей Ильич Белогубов сайланды.

***• Кара. Чагыштыр. Нәтиҗә яса.***

# Пенсия артачак

Русиянең Федерация Советы картлык буенча пенсиянең минималь күләмен арттыру турында законны хуплады.

1 октябрьдән минималь пенсия-76.533,ә 1 декабрьдән 84.186 сум булачак.Моны тормышка ашыру өчен ай саен өстәмә рәвештә 3,4 трлн. сум акча тотылачак.

**Фараз** Куллану бәяләре,бераз туктап торганнан соң,октябрь аенда кабат үсә башлаячак.Алар сентябрь белән чагыштырганда 1,4 процентка үсәчәк.Азык-төлек бәясе 1,2 процентка,ә башка товарлар бәясе 1,9 процентка артыр дип көтелә.Түләүле хезмәт күрсәтүнең 3,2 процентка үсү ихтималы бар.

**Сан** Бер депутатны асрау һәм эшләтү өчен аена 125 миллион сум акча кирәк.Бу-уртача 123 кешенең айлык хезмәт хакы дигән сүз.

# ХӘЛ КЫЛАСЫ ЭШЛӘР КҮП ӘЛЕ

## *(Хакимияттә киңәшмә)*

Дүшәмбе көнне район хакимиятендә хуҗалык җитәкчеләре, агропромышленность комплексының эшкәртү һәм хезмәт күрсәтү предприятиеләре һәм оешмалары башлыклары катнашында узган киңәшмәнең башында район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев анда катнашучыларны шул көнне генә район авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе начальнигы итеп билгеләнгән, моңа кадәр Әлки районының «Хлебодарский» совхозы директоры булып эшләгән Фердинанд Мидхәт улы Дәүләтшин белән таныштырды.

Көнүзәк мәсьәләләргә күчеп, Юрий Владимирович көзге һава торышы ашыктырган шартларда кичектергесез зур эшләрне башкаруда барлык хуҗалыкларда да җаваплылыкның бердәй дәрәҗәдә булмавына басым ясап үтте. Аерым алганда, кукурузның силоска дигәнен тизрәк җыеп бетереп, аның орлыкка калдырылганын да массовый төстә ала башларга бик вакыт. Кызганычка каршы, соңгысына әлегә Мичурин исемендәге, «Әлмәт» һәм «Кондырча» хуҗалыкларында гына тотындылар әле. Чәкәннәрдәге кукурузның дымлылыгы төшә барган шартларда аны җыеп алуны һаман да суза килүне берничек тә аклап булмый.

Шикәр чөгендере казу кебек мөһим эшкә инде барлык хуҗалыкларда тотынсалар да, бу эшнең барышы да бердәй түгел әле. Кичәге көнгә район буенча татлы тамыр барлык мәйданның өчтән береннән диярлек казып алынды. «Кондырча», «Төрнәс»тә аны барлык мәйданның 66 -68, «Дуслык»та 78 процентында, «Киекле», «Игенче», «Татарстан»,Кузнецов исемендәге, «Рассвет» хуҗалыкларында 41 - 44 процентында казып алган бер вакытта «Комбайн», «40 лет Победы», «Таң»да, Агрохимервис», МСО, сөт - май комбинаты ярдәмче хуҗалыкларында казылган мәйданнар санаулы гектарларда гына әле. Иптәш Терентьев бу җәһәттән хуҗалыкларда чөгендер казыту комбайннарының җитештерүчәнлеге гаять түбән булуын искәртеп, аларны нефтебаза ярдәмче хуҗалыгындагыча ике сменада эшләтүгә күчүне бурыч итеп куйды. Шикәр чималын заводка озатуда да ашыга төшәргә кирәк. Заводка 11 мең тоннадан артык чөгендер китерелсә дә, аның яртысыннан күбрәге дүрт - «Кондырча», Хафизов исемендәге, Кузнецов исемендәге, «Киекле» хуҗалыклары исәбендә булуы уйландырырлык, Соңгы бер көндә ташылган 2300 тонна чамасы чималның да яртысыннан артыгы шул дүрт хуҗалыктан керде. Киңәшмәдә тапшырыла торган чималның чисталыгы һәм шикәрлелеге мәсьәләсендә хуҗалыклар белән шикәр заводы арасында мөнәсәбәтләргә ачыклык кертү зарурлыгы да кабыргасы белән куелды, шул ук вакытта тапшырылган чөгендер өчен түләү мәсьәләсен дә ахыргача хәл итеп бетерәсе бар.


Ю.В.Терентьев хуҗалыкларда туңга сөрүнең барышына да тукталды. Бу чара планлаштырылган мәйданның 69 процентында уздырылды инде, әмма эш темпы элеккечә үк бер үк хуҗалыкларда югары, икенчеләрендә һаман да түбән әле. Бу җәһәттән эш фронты азайган хуҗалыклардагы техниканы арттарак калучыларга булышка җибәрү чараларын күрү дә зыянга булмас иде. Андый килешүгә ирешкән хуҗалыклар бар да инде.

Киңәшмәдә киләсе ел уңышы турында кайгырту йөзеннән уҗымнарны тамырдан тукландыру һәм фундазол препараты белән эшкәртү, шулай ук киләсе елга чөгендер чәчелачәк кырларга раундап кертү кебек чараларга, сабан ашлыгы орлыкларын калибрлап тиешле кондициягә җиткерү кебек эшләргә дә җитди карарга кирәклеге ассызыкланды.

Икенче бер мөһим тармак - терлекчелектә көнүзәк бурыч малларны абзарларга кайтарып бетерүне ашыктыру зарур икәнлеген дә кайбер хуҗалыкларга карата кабатларга туры килә әле.

Иптәш Терентьев киңәшмә ахырында октябрь башында узачак көзге сабантуйга әзерләнү һәм аны уздыруга кагылышлы мәсьәләләргә тукталып үтте. Хакимият башлыгының социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Р.Ногъманова бу хакта аерым сүз алып сөйләде, ул шулай ук өлкәннәр унконлеген үткәрүгә кагылышлы мәсьәләләргә дә җентекләп тукталды.

## Бары «Дуслык» кына сезгә район хәбәрләрен җиткерер!




***Хөрмәтле дуслар!***

**1997 елның 8 сентябреннән 1998 елның беренче яртыеллыгына газетага язылу бара. Язылу бәясе ярты елга 26.400, өч айга - 13.200, бер айга - 4.400 сум.**

**Район газетасына язылырга ашыгыгыз! Ул һәрвакыттагыча сезгә яңалыклар, хәбәрләр, кызыклы киңәшләр белән бергә атналык телетапшырулар программасын да даими биреп барачак.**

Кадерлеләрем минем...

# «И ходай, сабырлык бир син безгә!»

# ЯЗМЫШЫННАН ҮЗЕ КАНӘГАТЬ

Кеше язмышына, бигрәк тә мондый озын гомерлесенә кагылу һәрчак кыен: тиешсез сүз, саксыз сорау белән онытылган әрнүне кузгатмагаем, дип куркасың. Әгәр инде бу җан тулысынча ачыла икән, синең өчен шуннан да зуррак бүләк булмый. Ә бу беренче карашка гадәти генә язмыш үзенә күп нәрсәне сеңдергән. Иң мөһиме - хезмәт, кешеләргә карата теләклелек, ачык күңеллелек белән сокландыра ул, шуңа да аның турында җылы хатирә калдырасыбыз бик килде.

Клавдия Петровна революциягә кадәр туган. Гаиләләре зур, эшкә батыр, кешеләргә ачык була. Өстәл артына өлкәннәрдән тыш тагы 8 бала утыра. Әмма Дала Мамыгына базарга килүче теләсә кайсы милләт кешесенә - татармы ул, чувашмы - өйдә урын да, тыйнак сый - хөрмәт тә табылып тора иде. Ата - аналары Петр Ефимович һәм Екатерина Ивановна өлкәннәр ризалыгыннан башка яратышалар, бары авыл руханиеның: « Яратышып кушылгач, гөнаһсы юк...» дигән сүзләре генә әтиләренең кырыс күңелен бераз йомшарта төшә һәм никахлашырга инде ата - ана ризалыгы белән баралар. Нәселләрендә кечкенәдән үк эшләп ашарга өйрәнеп үсәләр, шуңа күрә Клавдия дә 12 яшеннән бабасы белән бергәләп кырга чыга, юк, җиләк җыярга дип түгел, ә җир сөрергә һәм чәчәргә өйрәнә, чаба һәм ура да белә, көлтә бәйләргә дә кулы ятып тора... Эшчән гаилә була алар. Тик менә 37 нче елларда гына бу гаилә дә туган җирләрен ташлап китәргә мәҗбүр ителә. Әнә шулай Төрнәскә килеп чыгалар алар. Ферма янындагы баракка урнашалар. Клавдиянең эшчәнлеге монда да ярап куя һәм бик күп еллар буе шул ферма юлын таптый ул. Иртән таң атканчы ук тора да, караңгылы - яктылы фермага, маллары янына атлый, сыерларын юып - чистартып чыга, тиресләрен җыештыра, аннан ясмык җебетеп, чөгендер турый, җилен тартып та ничә сәгатьләп вакытын үткәрә. Тиз - тиз эшләргә тырыша ул, ни әйтсәң дә өйдә авыру әтисе, берсеннән берсе кечкенә балалары бит. Ташландык группа малларын бирәләр аңа һәм Клавдиягә аларны рәткә керткәнче күпме азапланырга туры килә. Бөтен шартын китереп карый ул аларны, Послушная яки Туманка дигән сыерларын иркәләп буйсындырса, Служанка яки Норвегиясен рәнҗетмәсеннәр дип көтүчеләр белән кычкырышуга кадәр барып җитә. Малкайлары хуҗаларының тырышлыгын буш итмиләр: Заветная дигән сыеры көнгә кырыгар литр сөт бирә хәтта. Иң яхшы савучы Клавдия Петровна Мизонованы сурәткә төшерергә дип совхозга кинохроникага кадәр килә, Мәскәүгә ВДНХга гына да өч тапкыр бара ул, үз тәҗрибәсе турында Колонналы зал мөнбәреннән торып сөйли, ялкынлы сүзләре белән башкаларны да күтәрә. Шул чакта, кырыгынчы елда әнисе алып кайткан түфли белән күлмәкне кызы Нина әле дә хәтерли. Клавдия Петровна үзе «Төрнәс» совхозының ул чактагы директорлары Алексей Никитич Кондренков, Иван Ильич Журавлев, Валентин Владимирович Ефимовны әле дә олылап искә ала: хуҗалык турында, кешеләр хакында кайгырталар иде, үзләрен дә җәлләмәделәр. Мул савым өчен бирелгән Мактау кәгазьләрен читтән торып агрокурслар бетергәнлеге турындагы таныклыклар белән бергә (ул чакта анысы мәҗбүри була) архивында кадерләп саклый ул.



...Клавдия Петровна тагын хатирәләргә бирелеп китә: күңел сандыгын бер ачып кына җибәр бит ул: елларының һәрберсе муенса мәрҗәннәредәй, барысы да бертөсле кебек, әмма бары тик беренче карашка гына шулай ул... Ул хатынның уңышларыннан бик көнләшүчеләр дә булды шул ул чакта. Печән чапканда артыннан берәүнең өттереп каравын тойганы, ә бераздан шул ук хатынның чалгысы белән «ялгыш кына» эләктереп алганлыгын бик ачык хәтерли. Хәтерләмәслекмени соң - аяктагы җөе барыбер калды бит.Шулай да күңелендә теге хөсетле хатынга булган үпкәне күптән онытты инде ул, аңа карап кына кешеләргә булган изгелеге дә, яхшылыгы да кимемәде...

... Сугыш еллары үзләре бай хатирә. Ир - атлар сугышка китеп беткәч бригадир булып калган Клавдиягә бик тә авырга килә ул чакта. Элек үзе карый торган маллар өчен генә җавап бирсә, хәзер бөтенесе турында да кайгыртырга, сыер савучыларны да тупларга, азыгын кайтартуны да оештырырга,сөтен дә илтергә кирәк. Арбасына сөт бидоннары тутырган атын урман аша куалап барган чакларда ничек шүрләвен бер үзе генә белә ул - урманда дезертирлар качып ята иде бит. Бер көнне шулай атлары чит нәрсәне тоеп алдылар да, алдырыпмы киттеләр - Клавдия ничек исән калганлыгына үзе дә гаҗәпләнә. Үзе эченнән ничек кенә курыкса да, моны кызларга сиздерми, киресенчә: «Әйдәгез әле, кызлар, без дә эшләмәсәк, кем эшләр соң бу эшләрне» дип аларны икенче көнне үк оештырып кырга алып китә...

Ул чакларда халыкның ничек исән калганлыгына хәзер исләрең китәрлек. Аякка кияргә чабата да юк - булганы тетелеп беткән, кешеләр үзләре ярымач: ипине кичен пекарнядан алып кайтып, эшләүчеләргә 500, калганнарга 200әр граммлап үзе бүлеп бирә ул. Шул минутларда күзләрен мөлдерәтеп торган балаларны кызганудаан елап җибәрмәскә үзендә ничек көч таба алгандыр ул...

Клавдия Петровна хәзер Норлатта, кызы Нина йортында яши. Әллә ни мулдан тормасалар да, күңел байлыгына кытлык кичерми. Яраталар аны, аның турында кайгырталар. 7 оныгы һәм оныкларының 12 баласының күбесен үзе багышкан ул. Шуңа да кечкенәләрнең берәрсенең кулы эшкә ятып тора икән: «Клавдия әбисенә охшаган» дип шаярталар.Үзе ул бик тә сабыр, ачык күңелле,беркайчан гайбәт сөйләмәс. Тышкы кыяфәте белән карт авыл мөгаллимәсенә тартым. Аллага ышана. Аның янына киңәш сорап еш киләләр. Яратып һәм үз итеп «губернаторша» дип йөртәләр аны.Заманында укырга - язарга өйрәнеп кала алмаса да, дөньядагыны белеп барырга тырыша, шуңа күрә кызы аңа «Аргументлар һәм фактлар»,«Труд», «Сельская жизнь»нан, «Благовести»дан, район газетасыннан кызыклы язмаларны укый. Хәтере бик яхшы аның, төрле чүп - чар белән тутырмыйча, киресенчә, изгелек, яхшылык белән сафландырып торганга күрәдер анысы. Күп вакыйгалар һәм исемнәрне хәтерли ул. Клавдия Петровна борынгы җырларны да бик күп белә. Кыскасы, башкалар инде әллә кайчан бүтәнгә алмаштырган кешелеклелек, югары әхлак кебек сыйфатларны һаман да таркатмыйча саклый ул. Күпьеллык хезмәте өчен нинди дә булса әҗер көтми Клавдия Петровна. Тик менә өйләренә телефон кертсәләр начар булмас иде - картайган көнендә бик тә кирәге чыгар иде анысының. Әле менә өлкәннәр декадасы уңаеннан районда күп кенә изге гамәлләр планлаштырылуы турында ишеткән ул. Менә шунда Клавдия Петровна Мизонова кебек ветеранның шушы бер теләгенә дә урын табылса ничек күңелле булыр иде...

**Т.НАЗАРОВА.**

## КОТЛЫЙБЫЗ!

**«Дуслык» район газетасы коллективы**



***өлкән хезмәттәшебез - шофер Камил Кыям улы Минабетдиновны чын күңелдән 65 яшь тулу көне белән тәбрик итә,сабыр холкы,ярдәмчеллеге,намуслы хезмәте өчен рәхмәт белдерә. Киләчәктә аңа исәнлек, озын гомер,тигезлек һәм татулык телибез.***

## Саннар




## фактлар

1997нче елның 1 октябренә районда барлыгы 16490 пенсионер исәпләнә. 1984нче елда бу сан 7 меңгә дә җитмәгән иде.

***

Ай саен пенсионерларга 4 миллиард 800 миллион сум акча бирелә.

***

Районда 505 Бөек Ватан сугышы ветераны,404 сугыш инвалиды яши.

***

Пенсионерларның максималь пенсиясе (компенсацияләрне кертеп) 335 мең сум тәшкил итә.Минималь пенсия күләме-219 мең сум.

# Җиденче тапкыр

Безнең тормышыбыз җиңел түгел. Шуңа да, аз тәэмин ителешле гаиләләргә,өлкәннәргә тиешле яшәү шартлары тудыру бүген актуаль мәсьәләләрнең берсе булып санала һәм аның мөһимлеге елдан-ел арта бара.

Быелгы өлкәннәр көненең үзенчәлеге нәрсәдә?

-Бу чара халыкара характерга ия,-ди халыкны социаль яклау идарәсе начальнигы Л.Н.Дилмөхәммәтова.-Беренче тапкыр Өлкәннәр көне 7ел элек билгеләп үтелгән иде.Быел ул «Төрле буыннар арасында мөнәсәбәт» девизы астында уздырыла.Биредә ике моментны билгеләргә кирәк-өлкән кешегә гаиләсендә һәм яшәү урынында мөнәсәбәт. Әгәр өлкән кешегә һәр икесендә дә игътибар җитә икән,димәк, уртак максатка ирешелгән.Билгеле,өлкәннәр мәшәкатьләре һәм кәефе турында без һәр көнне,һәр сәгатьтә кайгыртырга тиешбез.Менә шундый мисал.Хәзер безнең шәһәрдә торакка аерата мохтаҗ 4 кеше бар.Беләсезме,ничек була ул?Туганнары «алтын таулар» вәгъдә итеп,әүвәл алардан фатирларын саттыралар,аннан өлкәннәр бу гаиләдә артык кашыкка әверелеп,баш очында түбәсез калалар.Безнең бүген торак хуҗалыгына үтенечебез бар:шундый очраклар буенча документлар әзерләгәндә,безне читтә калдырмасыннар иде.

Декада кысаларында өлкәннәргә игътибар өчләтә артсын иде.Өй түбәләрен,коймаларын ремонтларга,утын китерергә,авыру картларның хәлен белергә,җылы эчкерсез обстановкада ветеранга акчалата ярдәм,азык-төлек җыелмасы тапшыруга гына безнең хәлебездән килә торган эш бит.Иң мөһиме,беркем дә читтә калмасын.Репрессияләнгән,яшәүдән туктаган предприятие,таралган төбәкләр яки Норлатка илнең төрле почмакларыннан килгән кешеләрне аерата истән чыгарырга ярамый.Бу безнең-халыкны социаль яклау органнарының бурычы.Ышанабыз: өлкәннәр көне һәм декадасын үткәрүдә, хезмәт коллективларыннан тыш,коммерция структуралары да катнашырлар.Моңа мисал бар:аларның берсе Чулпан өлкәннәр йортында яшәүчеләр өчен чәй янына җыелмалар әзерләде.

Тагын.Без өлкәннәр көне һәм декадасы барышында картлардан кергән барлык үтенечтеләкләрне һичшиксез бәян итәчәкбез.

**Т.АЛЕКСЕЕВА язып алды.**

## ПРИВИВКАГА ЧАКЫРАБЫЗ

. Татарстан Республикасында 1990 елдан дифтерия инфекциясе белән авыру кискен күтәрелеш алды. Массакүләм иммунизация үткәргәннән соң, 1996 елдан авыру кими башлады һәм 1997 елның 7 аенда алдагы елның шул чоры белән чагыштырганда 5,6 тапкырга кимеде. Әмма 50-56 яшьлек дифтерия белән авыручылар арасында 2 үлем очрагы булу 40 яшьтән узган, ягъни 1993-1995 елларда бер тапкыр гына прививка алган кешеләр арасында әлеге эшне ары таба да активлаштыру зарурлыгын күрсәтә. Моның өчен Октябрь район үзәк шифаханәсе тарафыннан организмга бернинди зыяны булмаган вакцина сатып алынды. Прививкалар районның барлык дәвалау-профилактика учреждениеләрендә тору урыны буенча врач караганнан соң бер тапкыр кулланыла торган шприцлар белән үткәрелә.

Хөрмәтле өлкәннәр, пенсионерлар! Район үзәк шифаханәсе поликлиникалары, амбулаторияләре, кабинетлары, участок шифаханәләре, фельдшер-акушерлык пунктлары сезне 8дән 16 сәгатькә кадәр үзләрендә көтәләр. Төшке ял-12 сәгатьтән 13 сәгатькә кадәр, шимбә-якшәмбе көннәрендә-ял.

**Д.ӘНДӘРОВА,**
**баш табибның эпидемиологик мәсьәләләр буенча урынбасары.**

## КОТЛЫЙБЫЗ!



*Югары Норлат авылында яшәүче сөекле әниебез **Өммегөлсем Гарифулла кызы һәм әтиебез Ильяс Нургали улы Мөхәммәтовларны** чын күңелдән көмеш туйлары белән котлыйбыз. Аларга эшләрендә зур уңышлар, гаилә бәхете һәм тынычлык телибез.*

*Яз танышып, көз кавышып*
*Янәшәдән киткәнсез*
*Авыл халкын сокландырып*
*Матур гомер иткәнсез.*
*Сез бәхетле бүген, чөнки икәү*
*Кайгы-шатлыкларны кичереп*
*Менә дигән ул һәм кызыгыздан*
*Үзегезгә алмаш үстереп.*
*Үз кулыгыз, үз көчегез белән*
*Төзегән мул уртак нигезнең*
*Рәхәтен дә икәү күрү өчен*
*Бирсен ходай сезгә тигезлек.*

***Иң изге теләкләр белән: әтиегез, әниегез, кызыгыз Ләйсән, улларыгыз Илсур, Илнур, Илфат һәм киленегез Фаилә.***

## КОТЛЫЙБЫЗ!

*Югары Норлат авылында яшәүче кадерле абыебыз **Ильяс Нургали улы**, тормыш иптәше **Гөлсем Гарифулла кызы Мөхәммәтовларның** 2нче октябрьдә көмеш туйлары. Кадерле абыебызны һәм апабызны көмеш туйлары белән котлап иң изге теләкләребезне, рәхмәтебезне белдерәбез. Сезгә исәнлек-саулык, җан тынычлыгы, гаилә бәхете телибез.*

***Иң изге теләкләр белән апаң, сеңелең һәм балалары.***

## Белдерүләр

### Сатабыз

**1887 елгы «Москвич - 41243», кыйммәт түгел.** Адрес: Циолковский ур., 9 - 41, 17.00 сәг. тән соң.

***

**Оригиналь фасонда «Ильдан» фирмасында каракүл белән аралаштырып тегелгән кара төстә 46 - 48 үлчәмдәге мутон тун, бәясе - 3млн. 800 мең сум.** Тел.: 5 - 25 - 50.

***

**1997 елгың августында чыккан ВАЗ - 21083.** Тел.: 5 - 18 - 62.

***

**Шәхси йорт сатыла яки өстәмә түләп ВАЗга алыштырыла.** Тел.: 5 - 15 - 01.

***

**Суккан кирпеч.** Тел.: 5 - 28 - 81.

***

**Ашыгыч рәвештә 1993 елгы әйбәт хәлдәге «Урал» мотоциклы сатыла яки терлеккә алыштырыла.** Тел.: 2 - 24 - 73.

***

**Каравыл Тавында дача участогы.** Тел.: 2 -13 - 28.

***

**Йорт (мунчасы, коесы. базы бар) сатыла яки 3 бүлмәле фатирга алыштырыла.** Төньяк поселогы, 15 нче позиция.



### Очрашуга чакырабыз

***18 октябрь 10 сәг.тә район культура йортында 2 нче мәктәпнең 60 еллыгына багышланган тантана була. Мәктәпне тәмамлаучыларны бәйрәмгә чакырабыз.***

**Мәктәп администрациясе.**

### Идел Буе региональ наркология үзәге

*Алкогольгә бәйлелектән һәм тәмәке тартудан бер сеанста кодлаштыру.* ***Табиб М.Б.Багрянцев.***

**Бездә генә!**

**Тулы анонимлык. Индивидуаль якын килү. Дәвалау барышында пациентның туганнарына да катнашырга рөхсәт ителә. Белешмә бирелә. Консультация, әңгәмә, кодлаштырудан соң күзәтү һәм ярдәм - бушлай!**

**Язылу һәм әңгәмә дәвалау көнне, җомга көннәрендә, 10 октябрьдә көндезге сәгать 2дә район мәдәният йорты бинасында уздырыла.**

РФ сәламәтлек саклау министрлыгыннан 1995 елның 16 гыйнварында бирелгән № 00164 - 30 лицензия.

## Тагын бер куркыныч яный

Планетада 20 миллионнан артык кешенең ризыкта һәм суда йод җитмәгәнлектән акылы зәгыйфь.

Русиядә дә бу хәл бик катлаулы. Эндокринология фәнни үзәге белгечләре тикшерүеннән күренгәнчә, Русиянең үзәк өлешендә халыкның 15-20 проценты зоб белән чирли, ә кайбер регионнарда бу сан 40 процентка кадәр җитә. Ә Мәскәүдә балаларның 90 процентына йод җитми.

Организмга йод җитмәү нәтиҗәсендә калкансыман биз авыруыннан тыш, яманшеш, параличлану, саңгыраулану барлыкка килүе бар. Боларны булдырмас өчен беренче чиратта йодлы тоз ашарга кирәк.

1990 елга кадәр илдә елына 500 мең тонна йодлы тоз кулланылган. Ә бүген, мондый тоз чыгаручы бик күп регионнар Русиядән аерым булгач, без бары тик 5 мең тонна гына йодлы тоз ашыйбыз. Нәтиҗәдә 50 миллионнан артык руссиялегә йод җитми.

-Бу проблеманы хәл итү өчен бер тиен акча да кирәкми, - ди Сәламәтлек саклау министры урынбасары, Русиянең баш санитар табибы Г.Онищенко.

-Бүген илдә тоз да, аңа кушар өчен йод препаратлары да бар. Бары тик оештыру эшләрен генә хәл итәргә кирәк.

## ЧЕККА БАРЫН ДА АЛЫП БУЛМЫЙ

*Минем кулымда 700 мең сумлык азык - төлек чегы җыелды. Андый сумманы мин һич сарыф итә алмыйм, кибеттә миңа бары борчак, ярма һәм тоз гына бирәләр. Бу шулай булырга тиешме икән?*

**В.ТИМОФЕЕВА,**
**НОРЛАТ шәһәре**

***РЕДАКЦИЯДӘН:** соңгы вакытта азык - төлек чекларын куллану мәсьәләсендә сорауларның беренчесе түгел иде бу. Шуңа да без бу мәсьәләгә ачыклык кертүен үтенеп райпо рәисе М.С.Моратовка мөрәҗәгать иттек. Ул безгә түбәндәгечә җавап бирде: «Азык - төлек чекларына без райпо кибетләреннән сөт, сөт продуктлары, ипи һәм икмәк - булка әйберләре, шул исәптән он һәм сатуда булган ассортиментта ярма, тоз, шырпы җибәрәбез».*



Мастер Иван Морозов участогыннан урман егучы Вакыйф Шәмсиев бәхет нәрсәдән тора дип үз - үзенә еш сорау бирә дип укучыны ышандырырга теләмибез, ул - фәлсәфи эзләнүләрдән ерак кеше. Әмма язмышына, авыр хезмәтенә зарланмый. Юкса, иртәнге 6 да торып вахтовкада 15 - 20 км. урман юлы үтеп эш урынына килү, кичкә кадәр пычкыңны кулыңнан куймау, кәүсәдә төгәл итеп чираттагы эзне билгеләү ай - һай җиңел түгел! Шулай яши Иван. Шәһәргә китәргә беркайчан теләге булмады. Баш очында түбәсе, гаиләсе бар, кайда да эшләргә. Ә эш хакын шулай ук бөтен җирдә азмы - күпме тоткарлыйлар. Күңелеңне биреп эшләгәч, үз хезмәтеңнән шатлыклар табарга була. Мәсәлән, аның пычкысы - шведлар эшләгән «Hysdvarna» безнең күтәрмәслек «Урал»ларың белән янәшә дә куймаслык уңайлы эш коралы. Шуңа өстәп - табигать кочагында эшлисең бит әле, аның саекмас байлыгы аяк астында. Инде авыр болытлар арасыннан күктән көзге вак яңгыр коелмый, көнең уен - көлке белән үтә икән - гомумән рәхәт. Тормышның җиңел бирелмәгәнен исә ул, эшче кеше, күптән аңлады инде, күңеле белән аның җиңеләясенә ышанычын җуймый. Һичшиксез җиңеләер. Бары бераз көтәргә генә кирәк.

**Н.АЗИЗОВ фотосында Тимерлек урманчылыгында 65 нче квартал. Урман чистарту бар. Агач ягучы Вакыйф Шәмсиев эш вакытында.**

## Рәхмәт белдерәбез

Кадерлебез Ганиев Камил Әхмәт улын соңгы юлга озатуда мораль һәм матди ярдәм күрсәткән, олы хәсрәтебезне уртаклашкан район мәгариф бүлеге, Киекле һәм Кизләү урта мәктәпләре коллективларына, авылдашларыбызга чын күңелдән рәхмәт белдерәбез.

**Хатыны, балалары, туганнары.**

## Рәхмәт белдерәбез

Сөекле улыбыз Илназны соңгы юлга озатуда мораль һәм матди ярдәм күрсәткән, олы хәсрәтебезне уртаклашкан «Норлатнефть» НГДУсы УТТсы, җәмәгать туклануы предприятиесе, район кулланучылар җәмгыяте, 4нче мәктәпнең укучылар һәм укытучылар коллективлары, күршеләребез, якыннарыбыз, туганнарыбыз һәм дусларыбызга чын күңелдән олы рәхмәтебезне белдерәбез.

**Әтисе, әнисе, сеңелесе.**

---

Киекле мәктәбе коллективы уллары **Геральд Фаикъ** улы **Хәмитовның** фаҗигале үлүе сәбәпле аның әти - әнисе, туганнарының тирән кайгысын уртаклаша.

---

Киекле җирле үзидарә Советы коллективы уллары **Геральдның** вакытсыз фаҗигале үлүе сәбәпле Кизләү урта мәктәбе директоры Фаикъ Сөләйман улы һәм укытучы Әлфия Хәммәтҗан кызы Хәмитовларның авыр кайгысын уртаклаша.

---

Октябрь район мәгариф бүлеге Кизләү урта мәктәбе директоры Фаикъ Сөләйман улы һәм татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әлфия Хәмәтҗан кызы Хәмитовларның сөекле уллары **Геральдны** вакытсыз югалтуларын зур кайгы белән хәбәр итә һәм мәрхүмнең якыннарының, туганнарының авыр хәсрәтен уртаклаша.

---

Кизләү урта мәктәбе укытучылар һәм укучылар коллективы, ире **Камил Әхмәт** улы **Ганиевның** вакытсыз үлүе сәбәпле, укытучы Луиза Хәким кызы Хөсәенованың, мәрхүмнең гаиләсенең, туганнарының тирән хәсрәтен уртаклаша.

---

Кизләү урта мәктәбе укытучылар һәм укучылар коллективы, ата-аналар уллары **Геральдның** фаҗигале төстә үлүе сәбәпле, Хәмитовлар гаиләсенең, туганнарының авыр кайгысын уртаклаша.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2338 данә.